**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-22, факс 3-44-14

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ;**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр. йорт 17. Тел. 3-44-22, факс 3-44-14

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

27.06.2024 № ПР-120

**Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы, «Актаныш муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» Актаныш муниципаль районы Советының 2007елның 01 августындагы 17/04 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2024 елның 15 июлендә Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе урынбасары вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрергә.

2. Расларга:

- 1 нче кушымта нигезендә конкурс комиссиясе составын;
- 2 нче кушымта нигезендә конкурс уздыру шартларын;
- 3 нче кушымта нигезендә конкурс комиссиясенең эш регламентын.

3. Кадрлар белән тәэмин итү секторы мөдиренә "Интернет" челтәрендә Актаныш мәгълүмат порталының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А. Ильясов

Актаныш муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына
__________ №-__ ,
1 нче кушымта

**Конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Ильясов Р.А. | комиссия рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Вахитов И.Р. | Комиссия рәисе урынбасары, муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Сираева Л.Р. | Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары; |
| Зәйнетдинов Б.Р. | комиссия рәисе урынбасары, милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе; |
| Касыймова Д.Р.- | комиссия секретаре, кадрлар белән тәэмин итү секторы мөдире |
| Мөхәммәтдинов И.Т. | комиссия әгъзасы, Башкарма комитетның юридик бүлеге башлыгы; |
| Сәрвәрова Н.Ф. | комиссия әгъзасы, Башкарма комитетның гомуми бүлеге башлыгы. |

Актаныш муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына
__________ №-__ ,
2 нче кушымта

**Конкурсны үткәрү шартлары**

Дәгъвачыларга квалификация таләпләре:

1) «дәүләт һәм муниципаль идарә» белгечлеге буенча югары профильле белем яки: муниципаль хезмәтнең муниципаль вазифасы белгечлеге буенча яки, муниципаль вазифа милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе урынбасары өчен тиң дип саналган белем;

2) Башкарма комитетның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе урынбасары муниципаль вазыйфасы өчен белгечлек буенча кимендә ике ел эш стажы;

Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә гариза бирә, аңа түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

1) үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган, 4 х 6 зурлыгындагы фотосурәт белән анкета;

2) паспорт яисә аны алыштыручы документ күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

3) кирәкле һөнәри белем бирүне, эш һәм квалификация стажын раслый торган документлар:

- һөнәри белем турында, шулай ук, гражданның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документларның эш (хезмәт) урыны буенча нотариаль яисә кадрлар хезмәтләре тарафыннан таныкланган күчермәләр;

- гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган хезмәт кенәгәсенең яисә башка документларның күчермәсе;

4) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны узуга каршы килә торган авыруы булмау турында документы;

5) авторлык эшләре (граждан теләге буенча).

Конкурс (документлар конкурсы, әңгәмә, һөнәри компетенцияне бәяләү) үткәрелә: 2024 елның 15 июлендә 10.00 сәгатьтә.

Гаризалар һәм конкурс документларын бирү срогы:

конкурс үткәрү турында хәбәр басылганнан соң 20 көн эчендә.

Гаризалар һәм конкурс документларын бирү урыны: 423740, Актаныш ав., Ленин пр., 17, өченче кат, кадрлар секторы, тел./факс (85552) 3-44-25

Актаныш муниципаль
районы Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына
__________ №-__ ,
3 нче кушымта

**КОНКУРС КОМИССИЯСЕНЕҢ ЭШ РЕГЛАМЕНТЫ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Вакантлы муниципаль вазыйфаны - мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе урынбасарын биләүгә конкурс үткәрү максатларында Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының конкурс комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә. Конкурс комиссиясе составы муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

1.2. Комиссия үз эшчәнлеген муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең Башкарма комитетның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасына дәгъва кылучыларны билгеләү турындагы боерыгы чыкканчы алып бара;

1.3. Конкурсны уздырганда комиссия федераль, республика законнарына һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми торган дәгъвачыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын куллана ала.

2. Комиссия утырышларын үткәрү тәртибе

2.1. Комиссия утырышы 2024 елның 15 июлендә 10.00 сәгатьтә үткәрелә.

2.2. Утырышны комиссия рәисе яки аны алмаштыручы зат алып бара.

2.3. Комиссия конкурста катнашу өчен тапшырылган документларны карый, әңгәмәләр үткәрә, конкурста катнашучыларның һөнәри һәм оештыру сыйфатларын бәяли.

2.5. Комиссия утырышы, комиссия составының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

2.6. Комиссия карарлары комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмәдә чагылдырыла.

Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

2.7. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган карар белән рәсмиләштерелә.

2.8. Комиссия карары кандидат катнашыннан башка кабул ителә.

2.9. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең конкурс җиңүчесен вакантлы вазыйфага билгеләү турында боерыгы чыгарыла һәм конкурс җиңүчесе белән хезмәт килешүе төзелә.